# КАРАР

Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге составына керүче Юртыш авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
Татарстан Республикасы

18 ноябрь 2024 г. №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, 22 «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены протоколы төзелгән, 2024 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлегенең Юртыш авыл җирлеге торак пунктында түбәндәге мәсьәлә буенча жыен узды «2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлегенең Юртыш торак пункты территориясендә даими яшәүче балигъ булган, СВО да катнашкан кешеләрдән һәм аларнын гаилә әгъзалары һәм 90 яшьтән узган өлкәннәрдән тыш, Һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- су башнясы территориясен киртә белән әйләндереп алуга;
- гидрант урнаштыруга;
- су башнясына насос сатып алуга;
- урам яктырткычларын ремонтлауга

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 298 (ике йөз туксан сигез) гражданнар җыенында катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 152 (йез илле ике) кеше кертелгән бу 51 % тэшкил итэ

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленгән: За позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 152 (йез илле ике) тавыш биргән; каршы позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш биргән.

Бу нигездә, гражданнар җыены:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге составына керүче Юртыш торак пунктында гражданнар җыены узган дип танылсын, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә.

2. «2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлегенең Юртыш торак пункты территориясендә даими яшәүче балигъ булган, СВО да катнашкан кешеләрдән һәм аларнын гаилә әгъзалары һәм 90 яшьтән узган өлкәннәрдән тыш, Һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергэ

- су башнясы территориясен киртә белән әйләндереп алуга;
- гидрант урнаштыруга;
- су башнясына насос сатып алуга;
- урам яктырткычларын ремонтлауга

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ» - кабул ителгән.

3. СВО да катнашкан кешеләрне һәм аларнын гаилә әгъзаларын һәм 90 яшьтән узган өлкәннәрне үзара салымнан азат итэргэ,

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Мәмдәл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Хокукый мәгълүматның рәсми сайтында бастырып чыгарырга https://pravo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәмдәл авыл җирлеге башлыгы
Биектау муниципаль районы Ф.Г.Сафиуллин